**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**города Азнакаево**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-20-31
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай**
**муниципаль районы**
**Азнакай шәһәре**
**БАШЛЫГЫ**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-20-31
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» 02 2019 ел № 72

Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре
территориясен планлаштыру һәм межалау проекты
буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында
«газ белән тәэмин итү һәм су белән тәэмин итү
объектлары төзелеше» линияле объектына урнашкан
адрес: Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль
районы, Азнакай шәһәре,
Әлмәт тракты урамы, 10 йорт

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына таянып, Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына, Азнакай шәһәрендә ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып, **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Азнакай шәһәре, Әлмәт тракты урамы, 10 нчы йорт адресы буенча урнашкан «газ белән тәэмин итү һәм су белән тәэмин итү объектларын төзү» линия объектына Азнакай муниципаль районы территориясен планлаштыру проекты һәм межалау проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Халык тыңлауларын үткәрү инициаторы булып Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башлыгы тора.

3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты — 2019 елның 21 февраленнән 2019 елның 22 мартына кадәр, сәг. 08.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр, тәнәфес 12.00 дән 13.00 сәгатькә кадәр;

- уздыру урыны – Азнакай шәһәре, Ленин урамы, 14 йорт;

- фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2019 елның 22 мартына кадәр кертелә ала торган адрес – Азнакай шәһәре, М.Солтангалиев урамы, 24 йорт, Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге (эш көннәрендә 8.00 дән 17.00 сәг.кадәр (төшке ашка тәнәфес 12.00 дән 13.00кә кадәр).

4. Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре Башкарма комитетына:

- Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Азнакай шәһәре, Әлмәт тракты урамы, 10 нчы йорт адресы буенча урнашкан «газ белән һәм су белән тәэмин итү объектларын төзү» линия объектына Азнакай муниципаль районы территориясен

планлаштыру проекты һәм межалау проекты буенча ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;

5. Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре территориясен планлаштыру проекты һәм межалау проекты турында фикер алышу буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составын расларга.

6. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru..

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Башлык М.З. Шәйдуллин

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәре Башлыгы карарына
кушымта
«___ »________2019 ел №______

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Әлмәт тракты 10 йорт адресы буенча урнашкан «газ һәм су белән тәэмин итү объектлары төзелеше» линия объектына, территорияне планлаштыру проекты һәм межалау проекты буенча фикер алышу буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| *Эшче төркем рәисе:* | |
| Шәмсетдинов А.Х. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| *Эшче төркем секретаре:* | |
| Аюпова Р.Р. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече (килешү буенча) |
| *Эшче төркем әгъзалары:* | |
| Солтанов М.И. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Шарафетдинова С.Ф. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Миндубаева Л.Ф. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Мугтасимов Р.Р. | Азнакай шәһәр Советы депутаты, " Азнакай муниципаль районының торак - коммуналь хуҗалыгы һәм төзекләндерү департаменты «муниципаль унитар предприятиесе директоры (килешү буенча) |
| Алчина Э.А. | Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәр Советы депутаты, «Универсал-Азнакай» ИК ҖЧҖ генераль директоры, совет әгъзасы (килешү буенча) |